| | |
|---|---|
| СОВЕТ СРЕДНЕТИГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ УРТА ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

Урта Тигәнәле ав.

15.08.2022 № 25

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге Советының 2013 елның 20 июнендәге 58 номерлы «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләре турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 2004 елның 29 декабрендәге 190 – ФЗ номерлы законның 31 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пунктына таянып,

**Урта Тигәнәле авыл җирлеге карар итте:**

1.«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре турында» Урта Тигәнәле авыл җирлеге Советының 20.06.2013 ел, № 58 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Территориаль зона Ж1 – шәхси торак төзелеше зонасы, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның түбәндәге төп төрләре белән тулыландырырга: авыл хуҗалыгы кулланышы; шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен; торак төзелеше; шәхси торак төзелеше өчен; блокланган торак төзелеше; күчмә торак; урта катлы торак төзелеше; автотранспортны саклау; үз ихтыяҗлары өчен гаражлар урнаштыру; элемтә хезмәте күрсәтү; көнкүреш хезмәте күрсәтү; сәламәтлек саклау; эшмәкәрлек; спорт; яшелчәчелек алып бару; бакчачылык алып бару.

1.2. Территориаль зона ОД1 - күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның

түбәндәге төп төрләре белән тулыландырырга: авыл хуҗалыгы кулланышы; питомниклар; автотранспортны саклау; капиталь төзелеш объектларыннан җәмәгатьчелек тарафыннан файдалану; коммуналь хезмәт күрсәтү; коммуналь хезмәтләр күрсәтү; коммуналь хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүче оешмаларның административ бинаралары; социаль хезмәт күрсәтү;социаль хезмәт күрсәтү йортлары; халыкка социаль ярдәм күрсәтү; элемтә хезмәте күрсәтү; тулай тораклар; көнкүреш хезмәте күрсәтү; сәламәтлекне саклау; мәгариф һәм агарту; мәдәни үсеш; фәнни эшчәнлекне тәэмин итү; эшмәкәрлек; эшлекле идарә; сәүдә объектлары (сәүдә үзәкләре,сәүдә-күңел ачу үзәкләре (комплекслар); базарлар; кибетләр;банк һәм иминият эшчәнлеге; җәмәгать туклануы; кунакханә хезмәте; күңел ачу; күңел ачу чаралары; хезмәт күрсәтүчеләрнең гаражлары; автомобиль юу; автомобильләрне ремонтлау; спорт; элемтә; фәнни-җитештерү эшчәнлеге.

1.3. Территориаль зона СХ1 – авыл хуҗалыгы җирләре зонасы җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның түбәндәге төп төрләре белән тулыландырырга: авыл хуҗалыгы кулланышы; үсемлекчелек; бөртекле һәм башка авыл хуҗалыгы культураларын үстерү; яшелчәчелек; тонизацияли торган, дару, чәчәк культуралары үстерү; бакчачылык; йөзем үстерү; җитен һәм киндер үстерү; терлекчелек; эре терлекчелек; җәнлекчелек; кошчылык; дуңгызчылык; умартачылык; балыкчылык; авыл хуҗалыгын фәнни яктан тәэмин итү; авыл хуҗалыгы продукциясен саклау һәм эшкәртү; кыр кишәрлекләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару; питомниклар; авыл хуҗалыгы җитештерүен тәэмин итү; печән чабу; авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү; эчке тәртипне тәэмин итү; яшелчәчелек алып бару; бакчачылык алып бару.

1.4. Территориаль зона СХ2 – авыл хуҗалыгы предприятиеләрен һәм корылмаларын урнаштыру зонасы җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның түбәндәге төп төрләре белән тулыландырырга: авыл хуҗалыгы кулланышы; үсемлекчелек; бөртекле һәм башка авыл хуҗалыгы культураларын үстерү; яшелчәчелек; тонизацияли торган, дару, чәчәк культуралары үстерү; бакчачылык; йөзем үстерү; җитен һәм киндер үстерү; терлекчелек; эре терлекчелек; җәнлекчелек; кошчылык; дуңгызчылык; умартачылык; балыкчылык; авыл хуҗалыгын фәнни яктан тәэмин итү; авыл хуҗалыгы продукциясен саклау һәм эшкәртү; кыр кишәрлекләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару; питомниклар; авыл хуҗалыгы җитештерүен тәэмин итү; печән чабу; авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү; эчке тәртипне тәэмин итү; яшелчәчелек алып бару; бакчачылык алып бару.

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урта Тигәнәле авыл җирлеге Советы бинасында махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

4. Карар халыкка рәсми рәвештә җиткерелгәннән соң үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Урта Тигәнәле авыл җирлеге Башлыгы**
**Совет Рәисе** **И.К.Хәмәтвәлиев**

СОВЕТ СРЕДНЕТИГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ